# ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ

*ФАСИЛ ӘХМӘТОВ музыкасы*
*МОСТАФА НОГМАН сүзләре*

Таң йолдызы, маяк бул син
Юлда иркәмә;
Нурларың белән аны син
Назлап иркәлә!
Аның кайтып килүен мин
Бик көтеп калам;
Аның өчен чын йөрәктән
Ашкынып янам.

Аның белән яшәү миңа
Җиңел шул чаклы!
Кая бармыйм, эшләрем — уң,
Көннәрем - якты.
Тормышым йолдызы итеп
Карыйм мин аңа.
Сүнмәс дәрт белән рухланып
Яшим дөньяда.